КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 июль г.Казань № 690

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 8 февраль, 96 нчы карары белән расланган 2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы

бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 8 февраль, 96 нчы карары белән расланган 2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

11 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешманың, оешма белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә оешманың субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Оешмалар, оешма белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә оешманың субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалык бирә.»;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Министрлык оешманың субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

23 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 8 февраль, 96 нчы карары белән расланган 2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия

иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин